**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**

**Иске Чаллы авыл Жирлеге**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, дом 20
тел.: 8 (84346) 79-4-53

Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур. 20 йорт
факс: 8 (84346) 79-4-53

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　Иске Чаллы ав.　　КАРАР

2025 елның " 09 " июне　　№21

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Иске Чаллы авылы Үзәк урамнан 200 метр ераклыкта (чокыр буйлап);
- Полевая урамыннан 100 метр ераклыкта (чокыр буйлап);

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү» дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы　　Р.С. Мусин